| | |
|---|---|
| **ГЛАВА НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА И ГОРОДА НУРЛАТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ҺӘМ НУРЛАТ ШӘҺӘРЕ БАШЛЫГЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 52 «29» 07 2015 ел

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру турында

«Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу турында» 2005 елның 21 июлендәге 108-ФЗ номерлы Федераль законны, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру турында» 2013 елның 10 апрелендәге 316 номерлы карарын, «муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»2014 елның 14 маендагы 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан, «Татарстан Республикасы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 18 июлендәге 523 номерлы карары һәм Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре җирле үзидарә органнарының һәм Әлмәт шәһәре дәүләт статистикасы бүлегенең (Нурлат шәһәре) (алга таба – Дәүләт статистикасы органы) 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру, әзерләү һәм уздыру буенча үзара хезмәттәшлеген координацияләү максатларында, **карар бирәм:**

1. 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны оештыру һәм уздыру өчен җаваплы орган итеп Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсен билгеләргә.

2. Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча район комиссиясен төзергә.

3. Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча район комиссиясе турында Нигезләмәне һәм аның составы, шулай ук 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча 2015–2017 елларга чаралар календарен расларга.

4. Нурлат муниципаль районының һәм Нурлат шәһәренең җирле үзидарә органнарына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә уздыру эшләрен координацияләү һәм оештыруга җаваплы дәүләт статистикасы органына ярдәм күрсәтергә.

5. Нурлат муниципаль районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә:

-дәүләт статистикасы органына крестьян (фермер хуҗалыклары) һәм индивидуаль эшкуарларның 2015 елның 1 гыйнварына алга таба төгәлләштереп, исемлекләрен, шулай ук 2015 елның 1 гыйнварына торышы буенча дәүләт ярдәме алган авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерүчеләр исемлеген, шуннан соң төгәлләштереп, җибәрергә;

- статистик мәгълүмат бирү, исәпкә алу кәгазьләрен тутыру өчен җаваплы район авыл хуҗалыгы оешмаларының вазыйфаи затларын укытуны тикшереп торуны гамәлгә ашырырга;

- районның авыл хуҗалыгы оешмалары тарафыннан исәпкә алу кәгазьләрен вакытында һәм дөрес тутырырга.

6. Нурлат районы дәүләт ветеринария берләшмәсенә 2015 елның 5 августына кадәр ветеринария хезмәте хезмәтләреннән файдаланучы шәһәр җирлекләре гражданнарның исемлекләрен, аннары 2016 елның 1 мартына кадәр төгәлләштерелеп дәүләт статистикасы органына тапшырырга.

7. “Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы”на дәүләт статистикасы органнарына Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә урнашкан җир биләмәләрен экспликацияләү буенча белешмәләр бирергә.

8. «Дуслык»(«Дружба», «Туслах») газетасы редакцияләре һәм «Нурлат» радиокомпаниясе редакцияләренә дәүләт статистикасы органына 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләүне һәм уздыруны мәгълүмати яктыртуда ярдәм күрсәтергә.

9. Нурлат муниципаль районының һәм Нурлат шәһәренең җирле үзидарә органнарына:

- дәүләт статистикасы органына дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле документларны һәм мәгълүматны бирергә;

- авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыюны һәм исәпкә алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклауны гамәлгә ашыручы затлар эше өчен телефон элемтәсе һәм җиһазы белән җиһазландырылган саклана торган биналарны, шулай ук транспорт чараларын бирергә;

- Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә яшәүче гражданнарны авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыюга җәлеп итүгә ярдәм итәргә;

- 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләрдән максатчан файдалануны тәэмин итәргә;

- 2015 елның 1 августына кадәр хуҗалык кенәгәләрен тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерергә;

- дәүләт статистикасы органына 2015 елның 15 августына кадәр, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, индивидуаль торак төзелеше һәм (яисә) авыл хуҗалыгы терлекләре булган Нурлат муниципаль районының һәм Нурлат шәһәренең торак пунктларында, шулай ук гражданнарның коммерциягә карамаган бакчачылык һәм яшелчәчелек берләшмәләрендә яшәүче халык хуҗалыклары исемлекләрен төгәлләштереп, дәүләт статистикасы органына бирергә.

10. Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлегенә авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыючы затлар эше өчен яраклы биналарны саклауны, исәп алу кәгазьләрен һәм авыл хуҗалыгы исәбен алуның башка документларын саклауны, шулай ук авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында белешмәләр җыючы затларның эш иминлеген тәэмин итәргә.

11. Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең ФКУ УИИ филиалы Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә урнашкан, үткәрү системасы, чәчү мәйданнары һәм (яисә) авыл хуҗалыгы терлекләре, кош-корт һәм умарта кортлары баш саны булган ярдәмче хуҗалыклар исемлекләрен дәүләт статистикасы органына тапшырырга.

12. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт статистикасы органына күчемсез милек объектлары турында исәпкә алу объектлары исемлекләрен төзү өчен кирәкле белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә алуда ярдәм күрсәтергә.

13. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы И.С. Сафиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль
районы башлыгы Р.А. Кузюров

Нурлат муниципаль районы башлыгының 2015 елның 29 июлендәге 52 номерлы карары белән расланды

"Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча район комиссиясе" турында НИГЕЗЛӘМӘ

1. 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча район комиссиясе Нурлат муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру өчен оештырылган.

2. Комиссия үз эшендә Россия Федерациясе Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып тора:

-2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру буенча Нурлат муниципаль районы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә башкарма органнарының килештерелгән гамәлләрен тәэмин итү;

- Нурлат муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрүгә бәйле мәсьәләләрне оператив хәл итү.

4. Комиссия аңа йөкләнгән бурычларны гамәлгә ашыру өчен Нурлат муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру вакытында дәүләт хакимияте башкарма органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеге мәсьәләләрен карый.

5. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Нурлат муниципаль районы территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны уздыру барышы турында дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары вәкилләрен тыңлау;

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм уздыру мәсьәләләре буенча Нурлат муниципаль районы башкарма хакимият органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан материаллар соратып алырга;

2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу мәсьәләләре буенча дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә башкарма органнарына тәкъдимнәр җибәрергә;

комиссия утырышына Нурлат муниципаль районы башкарма хакимияте һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм вазыйфаи затларын, иҗтимагый-

дини берләшмәләр вәкилләрен, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен, белгечләрне чакырырга;

6. Комиссия составы Нурлат муниципаль районы башлыгы тарафыннан раслана.

7. Комиссия комиссия рәисеннән, комиссия рәисе урынбасарыннан, комиссия әгъзаларыннан һәм секретарьдан тора.

Комиссия рәисе булмаганда яисә аның кушуы буенча рәис вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

8. Комиссия утырышлары комиссия рәисе раслаган эш планына туры китереп үткәрелә. Комиссия утырышлары, әгәр аларда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала.

9. Комиссия карарлары Комиссия рәисе яки аның урынбасары тарафыннан имзаланган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә.

Район хакимияте башлыгы карарын таләп итүче мәсьәләләр буенча Комиссия билгеләнгән тәртиптә тиешле тәкъдимнәр кертә.

10. Комиссия эшен оештыру-техник яктан тәэмин итү Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы буенча дәүләт статистикасы хезмәте органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Нурлат муниципаль районы башлыгының 2015 елның 29 июлендәге 52 номерлы карары белән расланды

Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерләнү һәм аны уздыру комиссиясе
СОСТАВЫ

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Кузюров Равил Әфраим улы | Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре башлыгы, комиссия рәисе |
| 2. | Сафиуллин Ислам Салих улы | Нурлат муниципаль районының Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| 3. | Алиева Наилз Ихсан кызы | Дәүләт статистикасы бүлегенең баш белгеч-эксперты, комиссия секретаре |
| *Комиссия әгъзалары:* | | |
| 4. | Ногманова Флюра Рәшит кызы | Нурлат муниципаль районы башлыгы урынбасары |
| 5. | Габдуллин Әсгать Касыйм улы | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 6. | Сафиуллин Нәгыйм Салих улы | Нурлат шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе |
| 7. | Белова Наталья Анатольевна | Әлмәт шәһәренең дәүләт статистикасы бүлеге белгече (Нурлат шәһәрендә) |
| 8. | Шәйхетдинов Рәмис Хамзә улы | “Нурлат муниципаль районы мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы” рәисе |
| 9. | Әһлиуллина Асия Вахит кызы | Нурлат муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палаталары |
| 10. | Маняпов Линар Нурислам улы | Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары |
| 11. | Нургатин Хафиз Шәрәфетдин улы | Россия Эчке эшләр министрлыгының Нурлат районы буенча бүлеге начальнигы |
| 12. | Морозова | Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль |

| | | |
|---|---|---|
| | Татьяна Владимировна | хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат бүлеге башлыгы |
| 13. | Лысов Василий Александрович | Нурлат РДВБ ДБУ башлыгы |
| 14. | Семенова Людмила Федоровна | халык санын алу мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкил |
| 15. | Сатдаров Айдар Галиаскәр улы | РФ ҖҮФХИнең ТР буенча идарәсенең Нурлат районы буенча филиалы начальнигы |
| 16. | Ганиев Рәфис Габбас улы | Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башлыгы |
| 17. | Хәйруллина Сәкинә Нурулла кызы | «Татмедиа» АҖ филиалы директоры, «Дуслык», «Дуслык», «Туслах»газетасы баш мөхәррире |
| 18. | Гиняева Резеда Әкрәм кызы | «Татмедиа» ААҖ филиалы «Нурлат» телерадиокомпаниясе директоры |

Нурлат муниципаль районы башлыгының 2015 елның 29 июлендәге 52 номерлы карары белән расланды

2015-2017 елларга Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре территориясендә 2016 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны уздыру буенча чараларның Календарь ПЛАНЫ

| **№ т/с** | **Чаралар исеме** | **Эшләрне тәмамлау вакыты** | **Җаваплы башкаручылар** |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| **2015 ел** | | | |
| | **Норматив-хокукый тәэмин итү** | | |
| 1. | 2014-2018 елларга Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуга әзерлек һәм аны үткәрү чараларының Календар планы проектын әзерләү | Ш квартал 2015 . | |
| | **Оештыру ягыннан тәэмин итү** | | |
| 2 | ИАС «Электрон хуҗалык кенәгәсе» һәм ВПН-2010 (КРОКларны бушату буенча) мәгълүмат массивларын файдаланып, 2006 елгы Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу базасында формалашкан шәхси ярдәмче һәм башка шәхси хуҗалыклар исемлекләрен актуальләштерү эшләрен оештыру. Исемлекләрне актуальләштерү буенча белгечләр белән гражданлык-хокукый килешүләр төзү | Май-июль 2015 | |
| 3 | Татарстан Республикасында Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу өчен картографик материал сайлау буенча эшләрне оештыру | IV квартал 2015 | |
| 4 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә әзерлек белән бәйле эшләрне башкаруга килешү нигезендә җәлеп ителә торган хезмәткәрләрне сайлап алу һәм найм буенча эшне оештыру | 2015 елда | |
| | **Норматив-хокукый тәэмин итү** | | |
| 5 | «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы территориясендә 2016 елда Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны уздыру турында» Нурлат муниципаль районы башлыгы карары проектын әзерләү | Ш квартал 2015 | |
| 6 | Нурлат муниципаль районында ВСХП буенча комиссияләр төзү | Ш квартал 2015 | |
| 7 | 2016 елга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча чараларның календарь планын раслау турында боерык проектын әзерләү | ноябрь 2015 | |
| | **Методик тәэмин итү** | | |
| 8 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу буенча республика комиссиясе эше өчен материаллар әзерләү | Ел дәвамында | |

| № т/с | Чаралар исеме | Эшләрне тәмамлау вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | **Оештыру ягыннан тәэмин итү** | | |
| 9 | Нурлат районында халык санын алу объектлары турында беренчел мәгълүматларны актуальләштерү, персонал саны буенча чыгымнар сметасын төгәлләштерү өчен | сентябрь-декабрь 2015 | |
| 11 | Исәпкә алу эшләрен оештыру:<br>- авыл, шәһәр җирлекләре буенча халык санын алуны үткәрү<br>- халык санын алу нәтиҗәләре нигезендә район буенча җыелма мәгълүматлар әзерләү | октябрь 2015<br><br>декабрь 2015 | |
| 12 | Югары һөнәри белем бирү учреждениеләре укытучыларын һәм студентларын Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында мәгълүмат җыюга җәлеп итү мәсьәләләре буенча район мәгариф учреждениеләре белән үзара хезмәттәшлек | ноябрь-декабрь 2015 | |
| 13 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу мәсьәләләре буенча мәгълүмати-аңлату эше программасын тормышка ашыру | IV квартал 2015 | |
| 14 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрүгә килешү нигезендә җәлеп ителә торган хезмәткәрләрне сайлап алу һәм найм буенча эшне оештыру | 2015 елда | |
| 15 | Нурлат муниципаль районында Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны норматив-хокукый һәм методологик тәэмин итү мәсьәләләре буенча авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Росреестр идарәсе һәм башка оешмалар белән ведомствоара хезмәттәшлек буенча эшне оештыру | 2015 елда | |
| 16 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында мәгълүмат җыючы затларның иминлеге мәсьәләләре буенча район буенча Эчке эшләр бүлеге белән хезмәттәшлек | 2015 елда | |
| 17 | Татарстан Республикасы буенча Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары исемлекләрен төзү | 2015 елда | |
| 18 | Татарстан Республикасы буенча Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү буенча башкарма хакимият органнары белән хезмәттәшлек | 2015 елда | |
| 19 | Районда Татарстан Республикасы буенча Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү буенча авыл җирлекләре исемлекләрен төзү һәм методологик ярдәм күрсәтүне контрольдә тоту | 2015 елда | |
| | **Технологик тәэмин итү** | | |
| 20 | Канцелярия кирәк-яракларын, матди-техник тәэмин итү чараларын, исәпкә алучы экипировкасын да кертеп кабул итү | 2015 елда | |
| **2016 ел** | | | |
| | **Мәгълүмати-аңлату эше** | | |

| № т/с | Чаралар исеме | Эшләрне тәмамлау вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 21 | Балалар рәсеме конкурсын үткәрүдә катнашу | апрель 2016 ел | |
| 22 | Матбугат конференцияләре, матбугат турлары, брифинглар һәм башка ИРР уздыру. Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны район массакүләм мәгълүмат чараларында мәгълүмат белән тәэмин итү, ТВ һәм радио каналларында тематик тапшырулар башлап җибәрү. Күрсәтмә агитация өчен материаллар әзерләү. | 2016 елда | |
| | **Оештыру ягыннан тәэмин итү** | | |
| 23 | Татарстан Республикасында төрле дин вәкилләре арасында аңлату эшләре алып баруда ярдәм күрсәтү турында дини конфессияләр вәкилләренә мөрәҗәгатьләрне әзерләү | I квартал 2016 | |
| 24 | Район буенча Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу буенча чыгымнар сметасын төгәлләштерү өчен беренчел мәгълүматларны актуальләштерү | апрель 2016 | |
| 25 | Исәпкә алу хезмәткәрләрен сайлауны оештыру, укыту һәм граждан-хокукый килешүләр төзү | апрель-июнь 2016 | |
| 26 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрү тәртибенә, исәп документларын тутыру, планшет компьютерларны куллануны да кертеп, өйрәтүне оештыру:<br>Татарстанстат белгечләре өчен ,<br>- вакытлы исәпкә алу хезмәткәрләре | май – июнь 2016 | |
| 27 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу объектлары турында мәгълүмат җыючы затларны сайлап алуны һәм яллауны оештыру һәм граждан-хокукый килешүләр төзү | май-июнь 2016 | |
| 28 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны уздыру | с01.07.2016 - 15.08.2016 | |
| 29 | Районда Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу документларын архивта саклау эшен оештыру | III-IV квартал 2016 | |
| 30 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу әзерләү, үткәрү һәм элемтә каналлары буенча Татарстанстат электрон массивларны (планшет компьютерлардан) тапшыру | 2016 елда | |
| 31 | Районда Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны үткәрү буенча хезмәткәрләрне найм буенча эшне оештыру | 2016 елда | |
| 32 | Вакытлыча исәпкә алу Хезмәткәрләре эше һәм исәпкә алу материалларын саклау, транспорт чаралары, элемтә һәм саклау өчен биналар бүлеп бирүне тикшереп тору буенча Татарстан Республикасы МБ башкарма комитетлары белән хезмәттәшлек | 2016 елда | |
| 33 | Районда Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу буенча район комиссиясе утырышларын әзерләү һәм оештыру | 2016 елда | |
| 34 | Татарстан Республикасында ВСХП матди кыйммәтләрен саклау эшен оештыру | 2016 елда | |
| | **Матди-техник һәм финанс яктан тәэмин итү** | | |
| 35 | Планшетлы компьютерлар алу (тикшерү һәм тестлаштыру) һәм аларны районга җибәрү | II квартал 2016 | |

| № т/с | Чаралар исеме | Эшләрне тәмамлау вакыты | Җаваплы башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 36 | Канцелярия кирәк-яракларын, матди-техник тәэмин итү чараларын, исәпкә алучы экипировкасын да кертеп алу | 1 июль 2016 | |
| | **Технологик тәэмин итү һәм мәгълүматларны автоматлаштырылган эшкәртү** | | |
| 37 | Сканерлар алу | июль 2016 | |
| 38 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу материалларын автоматлаштырылган эшкәртү өчен программа чараларын урнаштыру һәм урнаштыру | август 2016 | |
| | | | |
| **2017 ел** | | | |
| | **Методик тәэмин итү** | | |
| 39 | Район буенча Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алуны әзерләү һәм үткәрү турында Татарстанстатка хисап әзерләү | П квартал 2017 | |
| 40 | Бөтенроссия авыл хуҗалыгы исәбен алу чорында матди кыйммәтләрне саклау эшен оештыру | 2017 елда | |

______________________________